**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 19 маендагы 1707 номерлы карары**

# Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 24 мартындагы 670 номерлы карары белән расланган Родина, Даурия, Гвардия һәм Гадел Кутуй урамнары чикләрендәге территорияне планлаштыру һәм ызанлау проектына үзгәрешләр кертү турында

Территорияне шәһәр төзелеше документлары белән тәэмин итү максатыннан, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 45 һәм 46 статьялары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 2 февралендәге 112 номерлы «Федераль башкарма хакимиятнең вәкаләтле органнары, вәкаләтле Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары карарлары нигезендә әзерләнә торган территорияне планлаштыру документларын әзерләү, территорияне планлаштыру документларын раслау турында карар кабул итү, мондый документларга үзгәрешләр кертү, мондый документларны яки аларның аерым өлешләрен гамәлдән чыгару, мондый документларның аерым өлешләрен кулланылырга тиеш түгел дип тану, шулай ук федераль һәм төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлекләр территорияләренә карата территорияне планлаштыру проектын әзерләү һәм раслау кагыйдәләрен раслау турында»гы карары нигезендә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 24 мартындагы 670 номерлы карары белән расланган Родина, Даурия, Гвардия һәм Гадел Кутуй урамнары чикләрендәге территорияләрне планлаштыру һәм ызанлау проектына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 15 августындагы 2714 номерлы, 2023 елның 5 июлендәге 1876 номерлы, 2023 елның 29 августындагы 2492 номерлы, 2024 елның 29 мартындагы 1218 номерлы, 2024 елның 2 октябрендәге 4161 номерлы, 2025 елның 12 сентябрендәге 2882 номерлы, 2026 елның 2 февралендәге 294 номерлы карарлары белән

кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), планлаштыру проектының аерым өлешләрен әлеге карарга кушымта нигезендә раслап, үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны, билгеләнә торган кызыл линияләрнең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән (хезмәт урынында файдалану өчен материал) тыш, «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 19 маендагы
1707 номерлы карарына
кушымта

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2021 елның 24 мартындагы 670 номерлы карары белән расланган**
**Родина, Даурия, Гвардия һәм Гадел Кутуй урамнары чикләрендәге**
**территорияне планлаштыру һәм ызанлау проектына**
**кертелә торган үзгәрешләр**

1. Кызыл линияләр, планлаштыру структурасы элементлары һәм капиталь төзелеш объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләре күрсәтелгән территорияне планлаштыру сызымы фрагментларын (1 нче чират) әлеге үзгәрешләргә 1, 2, 3 номерлы кушымталар нигезендә редакцияләргә.

2. Кызыл линияләр, планлаштыру структурасы элементлары һәм капиталь төзелеш объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләре күрсәтелгән территорияне планлаштыру сызымы фрагментларын (2 нче чират) әлеге үзгәрешләргә 4, 5, 6 номерлы кушымталар нигезендә редакцияләргә.

3. Кызыл линияләрнең характерлы нокталары күрсәтелгән территорияне планлаштыру сызымы фрагментларын әлеге үзгәрешләргә 7, 8, 9 номерлы кушымталар нигезендә редакцияләргә.

4. Билгеләнә торган кызыл линияләрнең характерлы нокталары координаталары исемлеген (кызыл линияләрнең характерлы нокталары күрсәтелгән территорияне планлаштыру сызымына кушымта) әлеге үзгәрешләргә 10 номерлы кушымта нигезендә редакцияләргә.

5. Территорияне план буенча үстерү характеристикалары турында нигезләмәдә:

5.1. 4.2 пунктта:

5.1.1. икенче абзацта «23 торак комплекс (ЖК)» сүзләрен «24 торак комплекс (ЖК)» сүзләре белән алыштырырга;

5.1.2. сигезенче абзацта «1 279 986» санын «1 293 486» саны белән алыштырырга;

5.1.3. тугызынчы абзацта «1 127 986» санын «1 141 486» саны белән алыштырырга;

5.1.4. унберенче абзацта «42 666» санын «43 115» саныы белән алыштырырга;

5.1.5. уникенче абзацта «37 600» санын «38 048» саны белән алыштырырга;

5.1.6. 3 таблицадагы «4 номерлы микрорайон (М-4)» бүлегендә:

5.1.6.1. «17,8», «45,64», «374 750», «12 491» саннарын шул ук тәртиптә «18,8», «48,20», «388 250», «12 941» саннары белән алыштырырга;

5.1.6.2. «Күпфункцияле комплекс объектларын план буенча урнаштыру зонасы» юлын төшереп калдырырга;

5.1.7. 5 таблицада:

5.1.7.1. «Күпкатлы торак төзелешен план буенча урнаштыру зонасы» юлында «54,80», «18,70» саннарын шул ук тәртиптә «56,0», «19,11» саннары белән алыштырырга;

5.1.7.2. «Уку-укыту һәм белем бирү билгеләнешендәге объектларны план буенча урнаштыру зонасы» юлында «32,79», «11,19» саннарын шул ук тәртиптә «31,2», «10,65» саннары белән алыштырырга;

5.1.7.3. «Инженерлык инфраструктурасы объектларын план буенча урнаштыру зонасы» юлында «2,1», «0,72» саннарын шул ук тәртиптә «1,7», «0,58» саннары белән алыштырырга;

5.1.7.4. «Гомуми файдаланудагы яшел үсентеләрне план буенча урнаштыру зонасы» юлында «19,30», «6,59» саннарын шул ук тәртиптә «19,7», «6,72» саннары белән алыштырырга;

5.1.7.5. «Урам-юл челтәрен план буенча урнаштыру зонасы» юлында «80,23», «27,38» саннарын шул ук тәртиптә «79,92», «27,29» саннары белән алыштырырга;

5.1.7.6. «Күпфункцияле комплекс объектларын план буенча урнаштыру зонасы» юлын төшереп калдырырга;

5.1.7.7. «Торак булмаган билгеләнештәге объектларны урнаштыру зонасы» юлында «72,5», «27,74» саннарын шул ук тәртиптә «74,2», «25,32» саннары белән алыштырырга;

5.1.8. 6 таблицада:

5.1.8.1. «Күпкатлы торак төзелешен план буенча урнаштыру зонасы» юлында «61,6», «21,02» саннарын шул ук тәртиптә «64,2», «21,91» саннары белән алыштырырга;

5.1.8.2. «Уку-укыту һәм белем бирү билгеләнешендәге объектларны план буенча урнаштыру зонасы» юлында «31,8», «10,85» саннарын шул ук тәртиптә «32,5», «11,09» саннары белән алыштырырга;

5.1.8.3. «Инженерлык инфраструктурасы объектларын план буенча урнаштыру зонасы» юлында «2,1», «0,72» саннарын шул ук тәртиптә «1,7», «0,58» саннары белән алыштырырга;

5.1.8.4. «Гомуми файдаланудагы яшел үсентеләрне план буенча урнаштыру зонасы» юлында «20,1», «6,86» саннарын шул ук тәртиптә «20,7», «7,06» саннары белән алыштырырга;

5.1.8.5. «Административ-эшлекле билгеләнештәге объектларны план буенча урнаштыру зонасы» юлында «4,5», «1,54» саннарын шул ук тәртиптә «1,0», «0,34» саннары белән алыштырырга;

5.1.8.6. «Урам-юл челтәрен план буенча урнаштыру зонасы» юлында «79,5», «27,13» саннарын шул ук тәртиптә «79,92», «27,29» саннары белән алыштырырга;

5.1.8.7. «Күпфункцияле комплекс объектларын план буенча урнаштыру зонасы» юлын төшереп калдырырга;

5.1.8.8. «Торак булмаган билгеләнештәге объектларны урнаштыру зонасы» юлында «64,9», «22,15» саннарын шул ук тәртиптә «63,2», «21,57» саннары белән алыштырырга;

5.1.8.9. түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

| **Капиталь төзелеш объектларын урнаштыру зонасы атамасы** | **Мәйданы, га** | **Территория өлеше, %** |
|---|---|---|
| «Мәдәни-ял итү билгеләнешендәге объектларны план буенча урнаштыру зонасы | 0,33 | 0,11 |
| Җитештерү һәм коммуналь-склад билгеләнешендәге объектларны урнаштыру зонасы | 1,62 | 0,55 |
| Транспорт инфраструктурасы объектларын план буенча урнаштыру зонасы | 0,33 | 0,11» |

5.1.9. 7 таблицадагы «М-4» бүлеген түбәндәге редакциядә бирергә:

| **Микрорайон номеры** | **Торак комплекс номеры** | **Фатирларның гомуми мәйданы, кв.м** | **Исәпләнгән халык саны, кеше** |
|---|---|---|---|
| «М-4 | ЖК-3 | 157700 | 5257 |
| | ЖК-4 | 89650 | 2988 |
| | ЖК-13 | 35200 | 1173 |
| | ЖК-17 | 14700 | 490 |
| | ЖК-19 | 37500 | 1250 |
| | ЖК-20 | 40000 | 1333 |
| | ЖК-24 | 13500 | 450» |

5.1.10. 9 таблицаны искәрмәләре белән түбәндәге редакциядә бирергә:

«9 таблица

**Күпкатлы торак төзелешен план буенча урнаштыру зонасы характеристикалары**

| Күрсәткеч атамасы | Күрсәткеч зурлыгы | |
|---|---|---|
| | **1 нче чират** | **2 нче чират** |
| Капиталь төзелеш объектлары характеристикалары | | |
| Капиталь төзелеш объектын план буенча урнаштыру зонасы мәйданы, га | 56,0 | 8,2 |
| Торак фондының максималь тыгызлыгы, мең кв.м/га | 29,5 | ** |
| Фатирларның гомуми мәйданы, кв.м | 1 141 486 | 152000 |
| Эчкә кертеп-кушып төзелгән торак булмаган билгеләнештәге биналарның гомуми мәйданы, кв.м | 105 402*** | 1 |
| Торак йортларда катларның максималь саны, кат | 25**** | 25 |
| Күпкатлы торак төзелешенең планлаштырылган халык саны, кеше | 38 048 | 5067 |
| Инфраструктура объектларының сыйдырышлылыгына карата булган ихтыяҗ | | |
| Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендәге урыннарга булган ихтыяҗ, урын | 3083 | 411 |
| Гомуми белем бирү учреждениеләрендәге урыннарга булган ихтыяҗ, урын | 6507 | 867 |
| Поликлиникаларда бер сменага килүчеләр санына булган ихтыяҗ, бер сменага килүчеләр саны | 750 | 100 |
| Торак йортларда яшәүчеләрнең автомобильләрен даими саклау өчен машина урыннары санына булган ихтыяҗ, машина урыны | 11415 | 1520 |
| Торак йортларга килүчеләр өчен автомобиль кую урыннарына булган ихтыяҗ, машина урыны | 2039 | 272 |
| Эчкә кертеп-кушып төзелгән биналар өчен автомобиль кую урыннарына булган ихтыяҗ, машина урыны | 1318 | 383 |

* Автомобильләрне даими саклау урыннарына булган исәпләнгән ихтыяҗ Казан шәһәр округының шәһәр төзелешен проектлаштыруның җирле нормативлары нигезендә үзгәртеп төзелә торган территорияне исәпкә алып киметелде.

** Рөхсәт бирү документларын әзерләү вакытына гамәлдә булган Казан шәһәр округының шәһәр төзелешен проектлаштыруның җирле нормативлары нигезендә, шул исәптән җир

кишәрлеге өчен дә, үзгәртеп төзелә торган территорияләрдә арттыру мөмкинлеге белән билгеләнә.
*** Шул исәптән эчкә кертеп-кушып төзелгән торак булмаган билгеләнештәге биналарның гомуми мәйданы түбәндәгечә: ЖК-8 (1) торак комплексында – 2600 кв.м, ЖК-8 (2) торак комплексында – 1750 кв.м, ЖК-9 торак комплексында – 30600 кв.м.
**** ЖК-10 торак комплексы өчен торак йортлардагы катларның максималь саны – 31»;

5.2. 4.3 пунктта:

5.2.1. 10 таблицадан соң җиденче абзацка «, ЖК-24» сүзләрен өстәргә;

5.2.2. 10 таблицадан соң ундүртенче абзацка «ЖК-22» сүзләреннән соң «, ЖК-24» сүзләрен өстәргә;

5.3. 4.4 пунктта:

5.3.1. алтынчы абзацта «16,» санынннан соң «17,» санын өстәргә;

5.3.2. егерме өченче абзацтан соң түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«- Казан шәһәре Башкарма комитетының 2017 елның 30 июнендәге 2405 номерлы карары белән расланган территорияне планлаштыру проекты территориясендәге йортларда яшәүчеләр өчен ЖК-24 территориясендә кимендә 463 машина урыны булдыру каралган;

- 9 номерлы юл территориясендә ЖК-24 халкы өчен муниципаль парковка урнаштыру каралган (48 машина урынына кадәр);

- Вознесенский тракты урамы территориясендә ЖК-6 халкы өчен муниципаль парковка урнаштыру каралган (кимендә 43 машина урыны)»;

5.4. 4.5 пунктта:

5.4.1. 4.5.1 пунктчада:

5.4.1.1. беренче абзацка «, Родина урамында Ø 500 мм диаметрлы [аны 101,78/98,37 тамгалы камерадан (Родина урамы, 20в адресы буенча урнашкан йорт каршында) 104,04/100,98 тамгалы коега (Родина урамы, 8а адресы буенча урнашкан йорт тирәсендә) кадәрге участокта күчереп салу шарты белән]» сүзләрен өстәргә;

5.4.1.2. беренче абзацтан соң түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«“Водоканал” муниципаль унитар предприятиесенең техник мөмкинлекләрен исәпкә алып, ЖК-24 торак комплексын су белән тәэмин итүнең алдан исәпләнгән йөкләнеше тәүлегенә 250 куб.м тәшкил итә»;

5.4.2. 4.5.2 пунктчада:

5.4.2.1. беренче абзацка «канализация коллекторына» сүзләреннән соң «, шулай ук Даурия урамындагы 1000 мм диаметрлы канализация коллекторына (Танк урамында, Рихард Зорге урамы, 13 йорттан Хөсәен Мәүлүтев урамы, 2 йортка кадәрге участокта, 1000-1500 мм диаметрлы коллекторның үткәрүчәнлеген арттыру шарты белән)» сүзләрен өстәргә;

5.4.2.2. беренче абзацтан соң түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«“Водоканал” муниципаль унитар предприятиесенең техник мөмкинлекләрен исәпкә алып, ЖК-24 торак комплексыннан хуҗалык-көнкүреш суларын чыгаруның алдан исәпләнгән йөкләнеше тәүлегенә 250 куб.м тәшкил итә»;

5.4.3. 4.5.3 пунктчада:

5.4.3.1. беренче абзацта «20» санын «21» саны белән алыштырырга;

5.4.3.2. беренче абзацтан соң түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«ЖК-24 территориясендә яңгыр һәм кар суларының исәпләнгән чыгымы секундына 46,2 л тәшкил итә»;

5.4.4. 4.5.4 пунктчада:

5.4.4.1. икенче абзацта «37» санын «38» саны белән алыштырырга;

5.4.4.2. өченче абзацтан соң түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«“Челтәр компаниясе” акционерлык җәмгыятенең техник таләпләре буенча ЖК-24 өчен электр белән тәэмин итүнең алдан исәпләнгән йөкләнеше – 1240 кВт»;

5.4.4.3. дүртенче абзацка «, “Совет” подстанциясе» сүзләрен өстәргә;

5.4.5. 4.5.5 пунктчада:

5.4.5.1. алтынчы абзацта «Проектлаштырыла торган котельный тарафыннан җылытылачак 5 (М-5) номерлы микрорайон объектлары өчен җылылык һәм кайнар су белән тәэмин итүнең гомуми күләме» сүзләреннән соң «(ЖК-23)» сүзләрен өстәргә;

5.4.5.2. түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«ЖК-24 торак комплексын җылылык белән тэмин итүне этаплап башкару каралган:

- 1 нче этапта – блоклы-модульле котельныйдан,

- 2 нче этапта – «Татэнерго» акционерлык җәмгыятенең җылылык белән тәэмин итүнең планлаштырыла торган үзәкләштерелгән челтәрләреннән.

ЖК-24 объектларын җылылык белән тәэмин итүнең алдан исәпләнгән йөкләнеше сәгатенә 2,43 Гкал тәшкил итә»;

5.4.6. 4.5.6 пунктчада беренче абзацта «20» санын «21» саны белән алыштырырга;

5.4.7. 4.5.7 пунктчага түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«“Газпром трансгаз Казан” ҖЧҖ тарафыннан ЖК-24 өчен, диаметры 108 мм булган уртача басымлы газүткәргечкә тоташтырып, күләме сәгатенә 340 куб.м булган блоклы-модульле котельныйны газ белән тәэмин итү өчен техник мөмкинлек бирелде»;

5.5. 4.6 пункттагы өченче абзацта «39,66» санын «20,69» саны белән алыштырырга;

5.6. 4.7 пунктны төшереп калдырырга.

6. Территорияне план буенча үстерү чираты турында нигезләмәдә:

6.1. 1.1 пунктта икенче абзацка «, ТЖ-24» сүзләрен өстәргә;

6.2. 1.5 пунктта:

6.2.1. өченче абзацта «20» санын «21» саны белән алыштырырга;

6.2.2. дүртенче абзацта «37» санын «38» саны белән алыштырырга;

6.2.3. бишенче абзацта «2» санын «3» саны белән алыштырырга;

6.2.4. алтынчы абзацта «11» санын «12» саны белән алыштырырга;

6.2. 1.6 пункттагы өченче абзацта «39,66» санын «20,69» саны белән алыштырырга;


6.3. 12 таблицада:

6.3.1. «ЖК-1, ЖК-2, ЖК-3, ЖК-4, ЖК-5, ЖК-6, ЖК-7, ЖК-8.1, ЖК-8.2, ЖК-10, ЖК-11, ЖК-12, ЖК-13, ЖК-14, ЖК-15, ЖК-16, ЖК-17, ЖК-18, ЖК-19, ЖК-20, ЖК-21, ЖК-22, ЖК-23» сүзләреннән соң «, ЖК-24» сүзләрен өстәргә;


6.3.2. «1 127 986» һәм «102 202» саннарын шул ук тәртиптә «1 141 486» һәм «105 402» саннары белән алыштырырга.

___________


Казан шәһәре Башкарма комитетының
2021 елның 24 мартындагы 670 номерлы карары
белән расланган Родина, Даурия, Гвардия һәм
Гадел Кутуй урамнары чикләрендәге
территорияне планлаштыру һәм ызанлау
проектына кертелә торган үзгәрешләргә
1 номерлы кушымта




Казан шәһәре Башкарма комитетының
2021 елның 24 мартындагы 670 номерлы карары
белән расланган Родина, Даурия, Гвардия һәм
Гадел Кутуй урамнары чикләрендәге
территорияне планлаштыру һәм ызанлау
проектына кертелә торган үзгәрешләргә
2 номерлы кушымта




Казан шәһәре Башкарма комитетының
2021 елның 24 мартындагы 670 номерлы карары
белән расланган Родина, Даурия, Гвардия һәм
Гадел Кутуй урамнары чикләрендәге
территорияне планлаштыру һәм ызанлау
проектына кертелә торган үзгәрешләргә
3 номерлы кушымта




Казан шәһәре Башкарма комитетының
2021 елның 24 мартындагы 670 номерлы карары
белән расланган Родина, Даурия, Гвардия һәм
Гадел Кутуй урамнары чикләрендәге
территорияне планлаштыру һәм ызанлау
проектына кертелә торган үзгәрешләргә
4 номерлы кушымта




Казан шәһәре Башкарма комитетының
2021 елның 24 мартындагы 670 номерлы карары
белән расланган Родина, Даурия, Гвардия һәм
Гадел Кутуй урамнары чикләрендәге
территорияне планлаштыру һәм ызанлау
проектына кертелә торган үзгәрешләргә
5 номерлы кушымта




Казан шәһәре Башкарма комитетының
2021 елның 24 мартындагы 670 номерлы карары
белән расланган Родина, Даурия, Гвардия һәм
Гадел Кутуй урамнары чикләрендәге
территорияне планлаштыру һәм ызанлау
проектына кертелә торган үзгәрешләргә
6 номерлы кушымта



Казан шәһәре Башкарма комитетының
2021 елның 24 мартындагы 670 номерлы
карары белән расланган Родина, Даурия,
Гвардия һәм Гадел Кутуй урамнары
чикләрендәге территорияне планлаштыру
һәм ызанлау проектына кертелә торган
үзгәрешләргә 7 номерлы кушымта



Казан шәһәре Башкарма комитетының
2021 елның 24 мартындагы 670 номерлы карары
белән расланган Родина, Даурия, Гвардия һәм
Гадел Кутуй урамнары чикләрендәге
территорияне планлаштыру һәм ызанлау
проектына кертелә торган үзгәрешләргә
8 номерлы кушымта



Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 24 мартындагы 670 номерлы карары белән расланган Родина, Даурия, Гвардия һәм Гадел Кутуй урамнары чикләрендәге территорияне планлаштыру һәм ызанлау проектына кертелә торган үзгәрешләргә 9 номерлы кушымта

